МЭР
ГОРОДА НИЖНЕКАМСКА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА ШӘҺӘРЕ
МЭРЫ

пр. Строителей, д. 12, г. Нижнекамск, 423570

Төзүчеләр пр., 12 нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

**КАРАР**

№ 6

07 апрель 2015 ел

**Түбән Кама шәһәр Советының «2014 елга Түбән Кама шәһәре бюджеты үтәлеше турында» карары проекты буенча гавами тыңлаулар үткәрү турында**

Түбән Кама шәһәрендә яшәүчеләрнең 2014 елга Түбән Кама шәһәре бюджеты үтәлеше турында хисап проекты буенча фикер алышуда катнашу хокукларын үтәү максатыннан, Түбән Кама муниципаль районының Түбән Кама шәһәре Уставының 21 статьясы нигезендә, **карар бирәм:**

1. Түбән Кама шәһәр Советының «2014 елга Түбән Кама шәһәре бюджеты үтәлеше турында» карары проекты буенча гавами тыңлаулар үткәрергә.

2. 2015 елның 10 апреленә кадәр әлеге карарны «Нижнекамская правда» газетасында бастырып чыгарырга.

3. Билгеләргә:

3.1. уздыру вакыты – 2015 елның 17 апрелендә 15 сәг. 30 минутта;

3.2.үткәрү срогы – 1 көн;

3.3. үткәрү урыны – Түбән Кама шәһәре, Төзүчеләр пр., 12;

3.4. фикер алышына торган мәсьәлә буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр кертү, чыгыш ясау хокукы белән гавами тыңлауларда катнашу өчен гаризалар тапшыру өчен адрес: Түбән Кама шәһәре, Төзүчеләр пр., 12, 216 нчы кабинет (эш көннәрендә 8.00 сәгатьтән 17.00 сәгатькә кадәр);

3.5. чыгыш ясау хокукы белән гавами тыңлауларда катнашу өчен гаризалар бирү вакыты – 2015 елның 12 апреленә кадәр.

4. Түбән Кама шәһәре башкарма комитетына, билгеләнгән тәртип һәм әлеге карарда билгеләнгән срокка туры китереп, Түбән Кама шәһәр Советының «2014 елга Түбән Кама шәһәре бюджеты үтәлеше турында» карары проекты буенча гавами тыңлаулар әзерләргә һәм үткәрергә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Түбән Кама шәһәре Мэры урынбасары Э.Р. Долотказинага йөкләргә.

Түбән Кама шәһәре Мэры А.Р.Метшин